**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлеге составына керүче Березовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2024 елның 12 апреле,** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе турында " 29.11.2023 ел, № 1532 Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезләнеп 22.11. 2013 № 909 (29.11.2023 no 1532 редакциясендә), Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Березовка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Березовка торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 26 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Березовка бистәсендәге эчке юлларны (ЩПС) ремонтлау Үзәк урам, Мәктәп урамы).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Березовка авыл җирлеге башлыгы** **Ф. Ф. Сәлманов**